Сабантуй

70

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ

Роберт МИҢНУЛЛИН,
«Сабантуй»ның баш мөхәррире.

«Яшь ленинчы» битләрен актарып утырам. Ниләр генә юк анда! Кемнәр генә язышмаган да, кемнәр турында гына язылмаган, нинди генә хәлләр тасвирланмаган да, кайсы гына вакыйгалар яктыртылмаган ул битләрдә... 70 еллык Татарстан тарихы, татар балаларының совет чорына туры килгән шатлык-кайгылары, өмет-хыяллары... Совет иле кичергән авырлыклар, фаҗигалар, дәһшәтле сугыш еллары... Һәммәсе дә бар анда. Бүген инде ул сәхифәләрне мыек астыннан гына елмаеп та, ул чаклардагы вакыйгаларга, малайларның, кызларның кылган эш-гамәлләренә ышанмыйчарак та укырга мөмкин. Безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез нинди беркатлы булганнар, янәсе. Ленинга, Сталинга, партиягә, коммунизмга ышанып яшәгәннәр, янәсе...

Әйе, бүгенгедән чыгып караганда, алар чыннан да беркатлы булганнар. Әмма ул малайлар, кызлар матур киләчәккә чын күңелдән ышанып яшәгәннәр, шул матур көннәр тизрәк килсен дип тырышканнар. Дулкынлана-дулкынлана күкрәкләренә октябрят значогы кадаганнар, муеннарына пионер галстугы бәйләгәннәр, зур горурлык хисләре белән комсомол билеты йөрткәннәр. Һәм, без уйлаганча, барысы да начар, барысы да ялгыш булмаган. Ул чакта да малайлар, кызлар сезнең кебек үк уйнаганнар, шаярганнар, күңел ачканнар, укыганнар, эзләнгәннәр, хыялланганнар, иҗат иткәннәр.

«Яшь ленинчы» битләрен актарганда, ул чорлардагы балаларның көчле рухына, иҗат дәртенә, пионер ялкынына сокланып туймалы түгел. Юкка гына мыни газетабызның яшь хәбәрчеләре соңыннан танылган әдипләр булып киткәннәр. Татарның атаклы әдәбият-сәнгать әһелләре «Яшь ленинчы»ны чыгаруда турыдан-туры катнашалар. Безнең редакциядә эшләгән, бездә иҗат мәктәбе узган каләм ияләрен бүген бөтен татар матбугатында күрергә була.

Газетабызның яңа исеменә дә өйрәндек. Дүрт ел бит инде «Сабантуй» булып чыгабыз. Ил тормышы белән, халык язмышы белән янып яшәгән балалар газетасы бүген дә заман белән, балалар белән бер сафта атлый. Заманалар үзгәрә, балалар да үзгәрә. Алар белән бергә газета да үзгәрә бара. Төп максатыбыз гына, кыйблабыз гына шул килеш кала — чын кеше тәрбияләү! «Сабантуй»да чыныгу алган малайларыбыз, кызларыбыз Тормыш дигән олы Сабантуйда сынатмаслар, туган Татарстаныбызның чын патриотлары булып үсәрләр.

БЕЗНЕҢ МӨХӘРРИРЛӘР

Шәһит Шаммазов (1924—29).

Һава Измайлова (1929—31).

Ләбиб Гыйльми (1931—37).

Гомәр Хәбибуллин (1937—41).

Венера Ихсанова (1961—1977).

Роза Туфитуллова (1977—1986).

АЛАР БЕЗДӘ ЭШЛӘДЕЛӘР



Сулдан уңга: М. Галиева, С. Әхмәтова, М. Миңлебаева, Г. Галиев, Г. Мөхәммәтшин, А. Палуев. 1936—37 еллар.

Беренче рәттә (сулдан уңга): М. Сөләйманова, Г. Хәбибуллин (редактор), Г. Кәтиев. Икенче рәттә: Ф. Исмәгыйлева, Г. Халитова, Ә. Бикчәнтәева, М. Дибаева, А. Бикҗанова, Ф. Мусина. 1940 нчы еллар.

Беренче рәттә (сулдан уңга): Шәрәф Мөдәррис, чуваш язучысы Н. Илбәк, В. Ихсанова, редакция кунагы Д. Паттерсон, С. Ибраһимова, чуваш язучысы Н. Евстафьев; икенче рәттә: Ш. Зәбиров, М. Шабай, Р. Шакирова, Л. Шәфикова, И. Сәмигуллина, Х. Зарипов, Р. Яхина; чуваш журналисты, Д. Зөбәерова, Ә. Сәләхетдинов.

БҮГЕНГЕГӘ — 70 АДЫМ

1923. Июнь аенда ялкынлы комсомол җитәкчесе Шәһит Шаммазов Габдулла Тукай исемендәге балалар йортында татар балаларының егерме кешелек беренче пионер отрядын оештырды. Отряд «Яшь пионер» исемендәге кулъязма газета чыгара башлады.

1924 елның 10 октябре. «Яшь ленинчы»ның беренче саны чыкты. Беренче хәбәрчеләребез: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Әмирхан Еники, Хатыйп Госман һ. б.

1934 елның 29 май санында газета пионерлар исеменнән горурлык белән: «Без хәзер — 154. 773 кә җиттек», — дип белдерде.

1934. Газета каршында Абдулла Алиш һәм Галимҗан Мөхәммәтшин беренче әдәби түгәрәк оештырды.

1941. Бөек Ватан сугышы башлангач, газета чыгуыннан тукталды. Әмма ул сугыш елларындагы «Пионер бите» булып «Кызыл Татарстан»да дәвам итте.

Сугышка кадәр газетада эшләгән мөхәррирләребез, хезмәткәрләребез, авторларыбызның күбесе яу кырында ятып калды.

1961. Газетабыз яңадан чыга башлады.

«Пионерлар — Ватанга!» дигән китап яздык.

1964. «Ленин васыятьләре буенча» дигән экспедиция үткәрдек.

1961. «Дуслык» нефть магистраленә, Казан-Уфа дуслык поездына 30 мең тонна тимер-томыр җыярга!» девизы астында эшләдек.

1963. «Яшь ленинчы» призына Йөгерешчеләр көнен үткәрдек.

1964. «Яшь терлекләрне пионер шефлыгына», «Ленин васыятьләре буенча» дип исемләнгән экспедицияләр игълан иттек.

1965. «Нинди иркен минем туган илем!» дигән темага иң яхшы шигырьгә, рәсемгә, фотога конкурс оештырдык.

«Татарстан пионеры» теплоходына тимер-томыр җыябыз» дигән ярыш оештырдык.

«Әдәплелек мәктәбе», «Танкырстан иле» рубрикалары барлыкка килде.

«Лачын» операциясен игълан иттек. Халык бәхете өчен көрәшкән Татарстан кызларын һәм улларын эзләп табыштык.

1966. «Балкыгыз, Ильич йолдызлары!» дигән альбом-эстафета чыгардык.

Татарстан чикләрендә дуслык учаклары яндырдык.

«Һәр мәктәптә спорт мәйданчыгы булсын!» дигән чакыру игълан иттек.

1967. «Бертуган галстуклар» рубрикасы астында чит ил пионерлары турында сөйләдек.

Стена газеталарына конкурс игълан иттек.

«Бәхәс» клубында звенолар турында сүз алып бардык.

АЛАР БЕЗДӘ ЭШЛӘДЕЛӘР

Беренче рәттә (сулдан уңга): Х. Халиков, Ф. Маликова, В. Ихсанова (редактор), С. Ибраһимова, Р. Миңнуллин, Н. Булатов. Икенче рәттә: Н. Седов, Ә. Сәгъдиева, М. Вәлиуллин, Ю. Денисов, Р. Яхина, Һ. Мөхәммәтгалиева, И. Сәмигуллина, Ф. Вагыйзова. 1974 ел.

Редакция хезмәткәрләре ветераннар белән очрашу вакытында. Беренче рәттә (сулдан уңга): И. Сәләхов, Ә. Бикчәнтәева, М. Дибаева, Ж. Тәрҗеманов (язучылар), Р. Туфитуллова (редактор), М. Зарипов (пединститут доценты); икенче рәттә: Н. Акмал, В. Нуриев, А. Гафиятов, И. Сәмигуллина, Ф. Бәдретдинова, Л. Лерон, Р. Яхина, Ф. Сафин (врач), Н. Седов. 1983 ел.

Редакция хезмәткәрләре космонавт М. З. Рафиков белән очрашу вакытында. Беренче рәттә (сулдан уңга): Р. Миңнуллин, М. Рафиков, Г. Садә; икенче рәттә: Р. Вәлиев, В. Нуриев, Ф. Хәмидуллин, А. Гафиятов, Й. Вәлиәхмәтов, Ф. Бәдретдинова, Р. Мортазина. 1987.

БҮГЕНГЕГӘ — 70 АДЫМ

1968. «Калкан» операциясе үткәрдек. Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез флотының данлы юлы турында шигырьләр, хикәяләр яздык, рәсемнәр ясадык.

1971. «Яшь ленинчы» автоколоннасына металл, «Ульяновлар Татарстан җирендә», «Яфрак» операциясе, «Яшь химиклар мәктәбе» дигән рубрикалар барлыкка килде.

1973. «Белемнән башка коммунизм юк», «Кешеләргә шатлык өләшик» (тимурчылар эше), «ГДР — фестиваль иле» дигән рубрикалар туды.

1974. «Туган ягым — яшел бишек» операциясе үткәрдек.

1974. В. И. Ленин залларына, бүлмәләренә смотр игълан иттек.

Газета РСФСР Верховный Советының «Почет грамотасы» белән бүләкләнде.

1974. «Иптәш» сәхифәсе ачылды. Бөтенроссия табигатьне саклау Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләндек.

«Тынычлык бакчалары», «Ватан бер ул, бердәнбер», «Без синең белән, Чили!», «Алар Ильичка ант иттеләр» операцияләре туды.

1980. Газета ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Комсомол даны» елъязмасына кертелде.

Хезмәт темасына түбәндәге рубрикалар барлыкка килде: «Әтиләр җире — безнең җир», «Кем булырга, нинди булырга?», «Хезмәтебез республика хезмәтенә кушыла».

1982. Газета Совет Тынычлыкны саклау комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

1983. Азык-төлек программасын үтәүне иң уңышлы яктырткан комсомол һәм пионер газеталары арасында беренче урынны алып, газета икенче мәртәбә ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Комсомол даны» елъязмасына кертелде.

1987. «Яшь ленинчы» призына малайлар арасында спорт ярышлары үткәрә башлауга 10 ел тулды.

1993. Балаларның яраткан герое Шәвәлигә 30 яшь тулды.

1991 елдан газета «Сабантуй» исеме белән чыга башлады. 1991—94 елларда түбәндәге рубрикалар барлыкка килде: «Татарстан тарихы», «Иман», «Каләмдәш», «Кети-кети», «Мөхәррир сүзе», «Яраткан җырчыларыбыз», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Бишенче тәгәрмәч», «Татар мөгаллимнәре», «Әйбәт буласым килә», «70 һөнәр» һ. б.

АВТОРЛАРЫБЫЗ

Татарстанның халык шагыйре С. Хәким (уңнан дүртенче) шәкертләре белән (уңнан сулга): Г. Рәхим, Р. Мингалим, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гаташ.

Шагыйрь Шәүкәт Галиев.

КДУның журналистика факультеты деканы Флорид Әгъзамов.

Татарстанның атказанган артисты Рамил Курамшин.

Фотохәбәрче Мидхәт Шакиржанов.

КДУ укытучысы Васил Гарифуллин.



Язучы Галимҗан Гыйльманов.

АВТОРЛАРЫБЫЗ

Тарихчы галимнәр Гамирҗан Дәүләтшин һәм Фаяз Хуҗин.

Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов.

Беренче классы очучы Рәшит Ибраһимов.

Язучы Фәнис Яруллин.

Фотохәбәрче Анатолий Андронов.

Фотохәбәрче Александр Колсанов.

Фотохәбәрче Наил Курамшин.

АЛАР БЕЗДӘ ЭШЛӘДЕЛӘР

ТГЖИ директоры Д. Т. Хәйруллина.

Шагыйрь Р. Харис.

Шагыйрь М. Шабаев.

Шагыйрь Р. Фәйзуллин.

Шагыйрь Х. Халиков.

Шагыйрь Р. Мингалим.

Язучы К. Кәримов.

Шагыйрь Л. Лерон.

Шагыйрь Р. Зәйдулла.

Шагыйрә Э. Шәрифуллина.

Язучы С. Зыя.

Язучы Р. Батулла.

Шагыйрь Зөлфәт.



Шагыйрь М. Әгъләмов.

Шагыйрь Р. Әхмәтҗанов.



Язучы Ә. Гаффар.

Шагыйрь Р. Закиров.

Язучы С. Ибраһимова.

Журналист И. Сәмигуллина.

Журналист Р. Яхина.

Язучы Н. Акмал.

Язучы Хәйдәр.

Язучы В. Нуриев.

Шагыйрә Ф. Мөслимова.

Шагыйрә И. Иксанова.

«САБАНТУЙ»НЫ БЕЗ ЧЫГАРАБЫЗ

Беренче рәттә (сулдан уңга): Алмаз Гыймадиев (корреспондент), Кадим Шакиров (шофер); икенче рәттә: Роберт Миңнуллин (баш мөхәррир), Әминә Гарипова (баш бухгалтер), Шәүкәт Галиев (редколлегия әгъзасы), Рәзинә Исмәгыйлева (корреспондент), Фәридә Вагыйзова (корреспондент), Госман Садә (мөхәррир урынбасары); өченче рәттә: Николай Седов (фотограф), Ләлә Гыймадиева (җаваплы секретарь), Рузилә Мөхәммәтова (корреспондент), Йолдыз Шәрапова (бүлек мөдире), Фирая Маликова (корректор), Илгизә Садриева (машинистка), Атлас Гафиятов (бүлек мөдире).

РӘССАМНАРЫБЫЗ

Илдар Әхмәдиев.

Леонид Насыйров.

Хәбир Әхмәтҗанов.

Светлана Привина.

Тавил Хаҗиәхмәтов.

Юрий Денисов.


Надыйр Әлмеев.

Герман Огородников.

Йосыф Вәлиәхмәтов.

Зөфәр Хәкимов.

АЛАР — БЕЗНЕҢ ДУСЛАРЫБЫЗ

1. «Волготрансгаз» производство берләшмәсенең Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр производство идарәсе җитәкчесе Ришат Габделислам улы Нурисламов берләшмәнең балалар бакчасында.

2. «Сабантуй» хәбәрчесе Р. Мөхәммәтова шул бакча балалары арасында.

Буклет Р. Г. Нурисламовның матди ярдәме белән чыкты.

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘР ГАЗЕТА ҺӘМ АНЫҢ УКУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

«Без барлык ватандашларыбызны һәм бөтен дөньяның хаклык сөюче гадел кешеләрен иң яхшы ниятләр белән, иң ягымлы сүзләр әйтеп, керсез күңелдән тәбрик итсәк иде.

Хәерле иртә, оланнар! Киләчәк тормышыгыз якты, бәхетегез мул, гомерегез озын булсын!

Гомәр БӘШИРОВ,
язучы. 1965».

«Кадерле балалар, хәрби эш нигезләрен яхшылап үзләштерүегезне, күпләп юк итү коралларыннан саклану чараларын яхшы белүегезне телим. Әтиләрегезгә һәм өлкән абыйларыгызга лаеклы алмаш булып үсегез.

В. ЧУЙКОВ,
Советлар Союзы Маршалы. 1970».

«Яшь ленинчы»да эшләвем белән мин аеруча бәхетле. Безне — өлкәннәрне, хатирәләргә бирелерлек итеп эшли, яна белүегез өчен рәхмәт сезгә.

Ибраһим СӘЛАХОВ,
язучы. 1968».

«Минем беренче рәсемнәрем 60 ел элек «Яшь ленинчы»да дөнья күрде. Рәссам булырга мин ул чакта хыяллана гына идем әле. Хыялым чынга ашсын өчен газета миңа бик күп ярдәм итте.

Харис ЯКУПОВ,
рәссам. 1984».

«Безнең кадерле яшь дусларыбызга һәм укучыларыбызга — Татарстан балаларына — чын йөрәктән кайнар сәлам! Тормышыгыз иң бәхетле, гел кояшлы булсын, балалар!

С. МИХАЛКОВ,
язучы. 1968».

«Татарстандагы яшь дусларым! Сез бөтен җирдә тынычлык һәм бәхет хыяллары чәчүчеләр булсагыз иде!

Морис КАРЕМ,
Бельгия шагыйре. 1969».

«Минем кадерле кечкенә һәм яшь дусларым — Татарстан малайлары һәм кызлары!

Мин сезнең бик яхшы укуыгызны һәм зур, кызыклы тормыш белән яшәвегезне телим! Якты хыялларыгызның һәммәсе дә тормышка ашсын.

СССРның очучы-космонавты
А. ЛЕОНОВ. 1966».

Зак. А-433. Тир. 5000. ТГЖИ.

Ә син
«Сабантуй»га
ЯЗЫЛДЫҢМЫ ӘЛЕ?